


Россия почтасы XVIII Ботенроссия «Ин яхшы хат дәресе» конкурсына йомгак ясады. Ин яхшы конкурс иншалары авторлары арасында оченче ел рәттән Мордовиядән яшь авторлар бар. 2019-2020 уку елы йомгаклары буенча «Ин яхшы хат дәресе» Федераль этабынын жинvчеләре һәм лауреатлары Россиянен 26 тобәгеннән 45 укучы һәм 4 укытучы булды. Республикабызны берьюлы оч яшь автор лаеклы кvрсәтте; аларнын икесе vз номинацияләрендә беренче урыннарны алды: Илья Начаркин «Истории случаются с теми, кто умеет их рассказывать…» номинациясендә жинvче дип табылды, ә Егор Бякин «Тот, кто с детства дружит с небом. Расскажу о своем самом увлекательном путешествии: настоящем или придуманном» номинациясендә беренче урынга лаек булды. Шунысы игътибарга лаек, ике жинvче дә 40нчы Саранск мәктәбенен 4 «б» сыйныфында укыйлар. Аларны укытучы Татьяна Кашкина әзерләгән.

Быел конкурснын федераль этабында Ләмберә районы Ләмберәнен беренче мәктәбе укучысы Дарина Магдеева да лауреат булды. Ә менә анын очен бу хатлар конкурсында беренче генә казаныш тvгел инде. 2019 елда «Бәхетле гаилә рецептлары» номинациясендә Дарина жинvче иде. Быел ул гаиләдә vзара монәсәбәтләр мәсьәләләренә икенче яктан карады һәм кабат аерылып торды. Дарина Магдееваны һәм башка призерларны (мәсәлән, Даниил Храмовны) югары квалификацияле, алдынгы рус теле һәм әдәбияты укытучысы Наилә Исмаил кызы Фазлова әзерләгән.

Барлык лауреатларны да конкурсны оештыручылардан дипломнар һәм бvләкләр котә. Үткән ел Дарина жинvче дипломы белән бергә ноутбук алган иде.

Мәгълvмати белешмә. «Ин яхшы хат дәресе» конкурсын Мордовиядә 10 елдан артык vткәрелә. Бу вакыт эчендә анда республиканын 5 меннән артык педагогы һәм укучысы катнашты. 2018 һәм 2019 елларда федераль этапларда безнен республикадан 6 укучы призер булды. Ә быелгы призерлар – югарыда.